**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня, улица
Ш.Марджани, дом 6

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Ш.Мәржани
урамы, 6нчы йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 июля 2026 ел № 214

**Әтнә район башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты каршындагы күренекле гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү турындагы материалларны карау буенча комиссия төзү турында" 29.12.2023 елның 854 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Әтнә район Советының «Гражданнар, Ватанны саклаучылар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатларында муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) исемнәр бирү, аларның исемнәрен үзгәртү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 14.12.2023 №211 карары нигезендә (09.07.2026 №42 үзгәрешләр белән), Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты карар бирә:

1. Әтнә район башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты каршындагы күренекле гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү турындагы материалларны карау буенча комиссия төзү турында» 29.12.2023 №854 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карар исемендә «атаклы гражданнар,» сүзләреннән соң «Ватанны саклаучылар,» сүзләрен өстәргә;

1.2. карар преамбуласын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

““Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү турында” 1993 елның 14 гыйнварындагы 4292-I номерлы Россия Федерациясе Законы, Әтнә муниципаль районы Уставы нигезендә, дәүләт, республика, муниципаль район үсешенә зур өлеш керткән һәм уңай йогынты ясаган күренекле гражданнар, Ватанны саклаучылар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар турында хәтерне саклау максатларында һәм Татарстан Республикасы Әтнә район Советының «Гражданнар, Ватанны саклаучылар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатларында муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) исемнәр бирү, аларның исемнәрен үзгәртү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 14.12.2023 №211 карарын үтәү максатларында Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты карар бирә:”;

1.3. карарның 1 пунктында «атаклы гражданнар,» сүзләреннән соң «Ватанны саклаучылар,» сүзләрен өстәргә;

1.4. карарның 2 пунктында «атаклы гражданнар,» сүзләреннән соң «Ватанны саклаучылар,» сүзләрен өстәргә;

1.5. карарга 1 нче кушымта «Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты каршындагы күренекле гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү турындагы материалларны карау буенча комиссия составын» кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

1.6. карарның 2 нче кушымтасында атаманы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты каршындагы күренекле гражданнар, Ватанны саклаучылар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү турындагы материалларны карау комиссиясе турында нигезләмә»;

1.7. Нигезләмәнең 1.1. пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әтнә район башкарма комитеты каршындагы күренекле гражданнар, Ватанны саклаучылар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү турындагы материалларны карау комиссиясе (алга таба - Комиссия) дәүләт, республика, муниципаль район үсешенә һәм (яисә) иҗтимагый мөнәсәбәтләргә зур өлеш керткән һәм уңай йогынты ясаган күренекле гражданнар, Ватанны саклаучылар, шул исәптән махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) катнашучылар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар турында хәтерне саклау, шулай ук Әтнә муниципаль районы территориясендә урнашкан муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) исемнәр бирүне координацияләү һәм бердәм алым булдыру, исемнәр куллануны тәртипкә китерү һәм аларны тарихи-мәдәни мирасның состав өлеше буларак саклап калу максатларында төзелгән.»;

1.8. нигезләмәнең 2.1. пунктындагы икенче һәм өченче абзацларында «гражданнар истәлегенә,» сүзләреннән соң «Ватанны саклаучылар, " сүзләрен өстәргә;

1.9. Нигезләмәнең 2.2. пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Әтнә муниципаль районында гражданнар, Ватанны саклаучылар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләрен караганда, Комиссия гражданнар, Ватанны саклаучылар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатларында муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) исемнәр бирү, аларның исемнәрен үзгәртү тәртибе турындагы Татарстан Республикасы Әтнә район Советының 14.12.2023 №211 карары белән расланган Нигезләмәгә таяна.»;

1.10. Нигезләмәнең 4.1. пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Комиссия утырышлары кирәк булган саен уздырыла, ләкин елына 2 тапкырдан да сирәгрәк түгел.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (https://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Җитәкче А.Ф. Каюмов

Татарстан Республикасы
Әтнә район башкарма комитетының
29.12.2023 ел, №854 карарына
1 нче кушымта
15.07.2026 № 214
карар редакциясендә

Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты каршындагы күренекле гражданнар, Ватанны саклаучылар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү турындагы материалларны карау комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Каюмов А.Ф. | Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе |
| Хәсбиуллин И.И. | Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе урынбасары |
| Гәләүтдинова Р.Ф. | Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитетының “Әтнә район мәдәният йорты” МБУ Мәдәни-ял итү оешмалары менеджеры, комиссия секретаре (килешү буенча) |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Абдуллина А.Р. | Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитетының “мәдәният бүлеге” муниципаль казна учреждениесе башлыгы |
| Фатыхов Р.Р. | Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитетының “мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе башлыгы |
| Мөхәммәтшин И.Ф. | Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы |
| Фидаева Р.Ф. | Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитетының архив секторы мөдире |

| | |
|---|---|
| Мөхәммәтҗанова А.И. | Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Әтнә районы буенча җәмәгать ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Галимҗанов Х.Ф. | Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы ветераннар Советы Рәисе (килешү буенча) |
| Гарипова М.Н. | Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Иҗтимагый советы рәисе (килешү буенча) |
| Муратова Г.Р. | Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы һөнәр берлекләре оешмаларының координация советы рәисе, Россия Федерациясе дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең һәм халыкка җәмәгать хезмәте күрсәтүнең Гомумроссия һөнәри берлеге Татарстан республика оешмасының ышанычлы заты (килешү буенча) |
| Гайнуллина Э.Р. | "Ватанны саклаучылар" махсус хәрби операциясендә катнашучыларга ярдәм итү дәүләт фондының Татарстан Республикасы буенча филиалының социаль координаторы (килешү буенча) |